ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АПАС МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ТУТАЙ АВЫЛЫ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

КАРАР

13 май, 2019 ел №131

«ҖИР САЛЫМЫ ТУРЫНДА» КАРАРЫНА ҮЗГӘРЕШЛӘР КЕРТҮ ХАКЫНДА

Россия Федерациясе Салым кодексы нигезендә Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Тутай авыл җирлеге Советы карар итә:

1. Тутай авыл җирлеге Советының 2014 елның 14 ноябрендәге 103 номерлы «Җир салымы турында "гы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«2. Салым ставкаларын түбәндәге күләмнәрдә билгеләргә:

1) авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җиргә яки торак пунктларда авыл хуҗалыгы кулланылышы һәм авыл хуҗалыгы җитештерү өчен файдаланыла торган җирләр составындагы җир кишәрлекләренә карата 0,3 процент;

2) торак фонды һәм торак-коммуналь комплекс инженерлык инфраструктурасы объектлары белән биләнелгән җир кишәрлекләренә карата 0,15 процент (торак фондына һәм торак-коммуналь комплексының инженерлык инфраструктурасы объектларына керми торган җир кишәрлегенә хокукына өлештән) яки торак төзелеше өчен сатып алынган (бирелгән) җир кишәрлегенә хокуктан тыш;

3) шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару, бакчачылык яки яшелчәчелек алып бару өчен сатып алынган (бирелгән) җир кишәрлекләренә, шулай ук "Гражданнар үз ихтыяҗлары өчен бакчачылык һәм яшелчәчелек алып бару һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында" 2017 елның 29 июлендәге 217-ФЗ номерлы Федераль законда каралган гомуми билгеләнештәге җир кишәрлекләренә карата 0,15 процент.";

4) башка җир кишәрлекләренә карата 1,5 процент.».

2.Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында, мәгълүмат стендларында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Апас муниципаль районының рәсми сайтында җирлек бүлегендә урнаштырырга.
3. Әлеге карар 2020 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.
4.Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Бакырчы авыл җирлеге башлыгына йөкләргә.

Тутай авыл җирлеге башлыгы Н.М.Насретдинова